Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты

# КАРАР

20 декабрь 2021 №42

«2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 29 декабрендәге 456-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү Программасын кушымта нигезендә расларга
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе: Ф.М.Фаттахов

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Зур Сәрдек авыл
җирлеге башкарма комитетының 20.12.2021
елның 42 номерлы карарына кушымта

# 2022 – 2030 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ

## ЭЧТӘЛЕК


1. Кереш
2. Программа паспорты
3. Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасының хәзерге торышы характеристикасы
4. Транспортка сорау, халыкның хәрәкәт итү күләме һәм характеры, Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә булган транспорт төрләре буенча йөк ташу фаразлары
5. Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын үстерүнең принципиаль вариантлары һәм максатчан күрсәткечләре буенча бәяләү
6. Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын үстерү буенча чаралар исемлеге һәм чараларны тормышка ашыру чираты
7. Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын үстерү чараларын финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын бәяләү
8. Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын үстерү чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү
9. Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү өлкәсендә институцион үзгәртүләр, эшчәнлекне хокукый һәм мәгълүмати тәэмин итүне камилләштерү буенча тәкъдимнәр

# 1. КЕРЕШ

2022 – 2030 елларга Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы түбәндәге документлар нигезендә эшләнде:

- «Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы» 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон;

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

- «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары

Программа Зур Сәрдек авыл җирлегенең (алга таба – җирлек) транспорт инфраструктурасын, шул исәптән җирлекнең социаль-икътисади һәм шәһәр төзелешен үстерүнең, транспорт соравы, халыкны йөртү һәм транспорт төрләре буенча йөк ташу күләме һәм характеры, автомобильләштерү дәрәҗәсе, юл хәрәкәте параметрлары үсешенең төп юнәлешләрен, юл хәрәкәте иминлеге, транспорт инфраструктурасының әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынтысы күрсәткечләрен билгели.

Программаның нигезен авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын үстерүнең төрле юнәлешләре буенча программа чаралары системасы тәшкил итә. Әлеге Программа авыл җирлегенең тотрыклы үсешенә юнәлдерелгән һәм Татарстан Республикасы транспорт комплексын реформалаштыру буенча дәүләт сәясәтенә тулысынча туры килә.

Программаның максатлары һәм бурычлары – җирлекнең тормышның башка өлкәләрендәге эшчәнлек белән балансланган һәм координацияләнгән транспорт инфраструктурасын үстерү, социаль-икътисадый үсеш өчен шартлар формалаштыру, халыкка, икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә транспорт хезмәте күрсәтүнең куркынычсызлыгын, сыйфатын арттыру, транспорт инфраструктурасының җирлекнең әйләнә-тирә мохитенә тискәре йогынтысын киметү.

## 2. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | **2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы** |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты<br>422122, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Үзәк ур., 141 |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты<br>422122, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Үзәк ур., 141 |
| Программаның җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты<br>422122, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Үзәк ур., 141 |
| Программаны эшләүнең максаты | Җирле әһәмияттәге транспорт инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләүгә булган ихтыяҗ нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең транспорт инфраструктурасын балансл, перспективалы үстерүне тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | Программаның максатына ирешү шартлары булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:<br>- халыкка, шулай ук җирлек территориясендә икътисади эшчәнлек субъектларына транспорт хезмәте күрсәтүнең куркынычсызлыгы, сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге;<br>- шәһәр төзелешен проектлау нормативлары нигезендә халык һәм икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен транспорт инфраструктурасы объектларының үтемлелеге;<br>халыкның хәрәкәттәге ихтыяҗлары, җирлек территориясендә пассажирлар һәм йөк ташуда икътисадый эшчәнлек субъектларының ихтыяҗлары нигезендә транспорт инфраструктурасын үстерү;<br>- җирлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеге белән балансланган транспорт инфраструктурасын үстерү;<br>- транспорт белән идарә итү өчен шартлар;<br>- хуҗалык эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәләренә карата юл хәрәкәтендә катнашучыларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итү өчен өстенлекле шартлар булдыру;<br>- башка транспорт чараларына карата гомуми файдаланудагы транспорт чаралары хәрәкәтенең өстенлекле шартларын булдыру;<br>- җирлектә җәяүлеләр һәм велосипедта йөрү өчен шартлар;<br>- гамәлдәге транспорт инфраструктурасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге. |

| | |
|---|---|
| Максатчан күрсәткечләр | Ремонтланган юлларның озынлыгы (асфальт-бетон җәю), км;<br>ЮТһ саны, берәмлек;<br>ЮТҺдә җәрәхәтләнүчеләр саны, кеше;<br>Төзелгән автомобиль юллары озынлыгы, км. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | Программа 2022-2030 елларга исәпләнгән |
| Таләп ителә торган капиталь кертемнәр күләме | Программа чараларын финанс ягыннан тәэмин итү муниципаль программалар кысаларында муниципаль районның җирле бюджеты чаралары һәм Татарстан Республикасы чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.<br>**2022 ел**<br>Программаларны финанслау күләме:<br>2 000 000 сум<br>эксплуатация һәм ремонт чараларын үтәү юлы белән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү;<br>җирле әһәмияттәге урамнарны һәм юлларны капиталь, агымдагы ремонтлау;<br>- җәяүлеләр тротуарларын ясау, юлларны карап тоту, даими грейдерлау, чокырларны ямау, юл билгеләрен урнаштыру, урамнарны яктырту өчен светодиод прожекторлар урнаштыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар.<br>**2023 ел**<br>Программаларны финанслау күләме:<br>2 000 000 сум<br>эксплуатация һәм ремонт чараларын үтәү юлы белән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү;<br>җирле әһәмияттәге урамнарны һәм юлларны капиталь, агымдагы ремонтлау;<br>- җәяүлеләр тротуарларын ясау, юлларны карап тоту, даими грейдерлау, чокырларны ямау, юл билгеләрен урнаштыру, урамнарны яктырту өчен светодиод прожекторлар урнаштыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар. |
| | **2024 ел**<br>Программаларны финанслау күләме:<br>2 000 000 сум<br>эксплуатация һәм ремонт чараларын үтәү юлы белән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү;<br>җирле әһәмияттәге урамнарны һәм юлларны капиталь, агымдагы ремонтлау;<br>- җәяүлеләр тротуарларын ясау, юлларны карап тоту, даими грейдерлау, чокырларны ямау, юл билгеләрен урнаштыру, |

| | |
|---|---|
| | урамнарны яктырту өчен светодиод прожекторлар урнаштыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар.<br>**2025 ел**<br>Программаларны финанслау күләме:<br>2 000 000 сум<br>эксплуатация һәм ремонт чараларын үтәү юлы белән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү;<br>җирле әһәмияттәге урамнарны һәм юлларны капиталь, агымдагы ремонтлау;<br>- җәяүлеләр тротуарларын ясау, юлларны карап тоту, даими грейдерлау, чокырларны ямау, юл билгеләрен урнаштыру, урамнарны яктырту өчен светодиод прожекторлар урнаштыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар.<br>**2026-2030 еллар**<br>Программаларны финанслау күләме:<br>10 000 000 сум.<br>эксплуатация һәм ремонт чараларын үтәү юлы белән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү;<br>җирле әһәмияттәге урамнарны һәм юлларны капиталь, агымдагы ремонтлау;<br>- җәяүлеләр тротуарларын ясау, юлларны карап тоту, даими грейдерлау, чокырларны ямау, юл билгеләрен урнаштыру, урамнарны яктырту өчен светодиод прожекторлар урнаштыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар.<br>Муниципаль берәмлек бюджетыннан финанслау ел саен чираттагы финанс елына бюджет формалаштырганда төгәлләштерелә. Финанслау күрсәткечләре, эшләнгән проект-смета документациясен һәм барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлардан акчаларны фактта бүлеп бирүне исәпкә алып, төгәлләштерелергә тиеш. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2030 елга түбәндәгеләр планлаштырыла:<br>1. Транспорт инфраструктурасын үстерү;<br>2. Гомуми файдаланудагы транспорт үсеше;<br>3. Җирлек юллары челтәрен үстерү;<br>4. Транспортның әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынтысын киметү;<br>5. Юл хәрәкәте иминлеген арттыру. |

## 3. ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТОРЫШЫ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Зур Сәрдек авыл җирлеге «Территорияләр чикләрен билгеләү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль

берәмлекләрнең статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелде.

Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясе Кукмара районының көнбатыш өлешендә район үзәгеннән 22 км ераклыкта урнашкан. Зур Сәрдек авыл җирлеге Байлангар,Зур Кукмара, Күкшел,Олыяз,Сәрдекбаш,Туембаш авыл җирлекләре белән чиктәш.

Зур Сәрдек авыл җирлегенең гомуми мәйданы 6960 га тәшкил итә. Зур Сәрдек авыл җирлеге халкы, Татарстан Республикасы Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең территориаль органы мәгълүматларына караганда, 2021 елга 3434 кеше тәшкил итә.

Зур Сәрдек авыл җирлегенең икътисади системасы агросәнәгать комплексын, кече бизнесны (хезмәт күрсәтүче өлкә) үз эченә ала. Җирлектә сәнәгать предприятиеләре юк. Авыл җирлегенең җитештерү нигезен авыл хуҗалыгы тәшкил итә.

Хуҗалыкның гамәлдәге җитештерү юнәлеше сөт җитештерү белән билгеләнә. Хуҗалык шулай ук эре мөгезле терлек ите, ашлык җитештерү һәм сату белән шөгыльләнә. Хуҗалыкта а/х культураларының районлаштырылган сортларын кертү, орлыкларның сыйфатын арттыру, нәселле терлек сату каралган.

Зур Сәрдек авыл җирлеге составына Зур Сәрдек авылы (административ үзәк), Чишмә-Баш,Кара-Елга,Купка,Аш-Бужи,Адай авыллары керә .

Авыл җирлегенең административ үзәге булып Зур Сәрдек авылы тора. Торак пунктның торак төзелеше шәхси торак йортлар һәм йорт яны кишәрлекләре белән тәкъдим ителгән.

Зур Сәрдек авыл җирлегендә түбәндәге хезмәт күрсәтү объектлары эшли: 5 Мәдәният йорты, 1 мәдәни-административ комплекс, 1 урта мәктәп, 4 урта мәктәп филиалы, 5 балалар бакчасы, почта отделениясе, теш кабинеты,5 ФАП, 20 кибет.

## 4. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ТРАНСПОРТКА СОРАУ, ХАЛЫКНЫҢ ЙӨРЕШЕ ҺӘМ ЙӨК ТАШУ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ХАРАКТЕРЫНЫҢ ҮЗГӘРҮЕ ФАРАЗЫ.

Транспорт – авыл җирлеге инфраструктурасының икътисадның барлык тармаклары һәм халыкның йөк һәм пассажирлар йөртүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерә, җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасында төрле продукция төрләрен күчерә, халыкка һәркем файдаланырлык булган транспорт хезмәте күрсәтә торган иң мөһим өлеше. Транспортның тотрыклы һәм нәтиҗәле эшләве халыкның пассажирлар йөртүгә булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерү һәм җирлекнең барлык предприятиеләренең уңышлы эшләве өчен кирәкле шарт булып тора. Авыл җирлегендә төп һәм бердәнбер пассажир транспорты булып такси һәм шәхси автотранспорт тора.

Зур Сәрдек авыл җирлегендә төп транспорт артерияләре булып, төп (главные) урамнар һәм торак төзелешендәге төп (основные) урамнар тора. Мондый урамнар: Зур Сәрдек авыл – Үзәк, Мәктәп, Тау асты, Тынычлык, Юл буе, Мәктәп яны, Яшьләр, Болын буе, Яр буе, Май, Кыр буе, Посадка буе, Тукай урамнары; Чишмә-Баш- Үзәк, Җиңү, Аргыяк,

Тынычлык, Яңа, Яшьләр, Тукай, ул. Посадка буе; Кара-Елга- Үзәк урам; Купка- Яшьләр, Пролетар, Совет урамнары; Аш-Бужи- Көнчыгыш, Яшьләр, Кыр буе, Үзәк, Яшьлек; Адай-Болын буе Яшьләр, Эшчеләр, Кояшлы, Татарстан, Үзәк, Мәктәп урамнары.Әлеге урамнар торак территорияләр эчендә һәм интенсив хәрәкәт юнәлешләре буенча төп (главный) урамнар белән элемтәне тәэмин итә.

1 нче таблица Зур Сәрдек авыл җирлеге чикләрендә урам-юл челтәре буенча гомуми мәгълүматлар

| № | Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | 2021 елга мәгълүматлар |
|---|---|---|---|
| 1 | Урам челтәренең гомуми озынлыгы | км | 37,77 |
| 2 | Урам челтәренең гомуми мәйданы | мең кв.м. | 151,08 |
| 3 | Урам-юл челтәре тыгызлыгы | км/км.кв.м | 0,25 |

Зур Сәрдек авыл җирлегенең урам-юл челтәрен анализлау нәтиҗәсендә транспортның эшен катлауландыручы түбәндәге сәбәпләр ачыкланды:

- урам һәм юлларның техник торышы канәгатьләнерлек булмау;
- машиналар йөрү өлешенең киңлеге җитмәү (4-5);
- грунт юлларның шактый озын булуы;
- урамнарның билгеләнеше буенча дифференциацияләү булмау;
- җәяүлеләр хәрәкәтен тәртипкә китерү өчен кирәкле тротуарлар булмау.

2 нче таблица Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеге

| № т/б | Автомобиль юлы яки урам исеме | Идентификация номеры | Озынлыгы, км |
|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы |
| | **Зур Сәрдек авылы** | | |
| 1. | Үзәк ур. | 92-633-416 ОП-МП-01 | 5,9 |
| 2. | Мәктәп ур. | 92-633-416 ОП-МП-02 | 0,9 |
| 3. | Тау асты ур. | 92-633-416ОП-МП-03 | 1,9 |
| 4. | Тынычлык ур. | 92-633-416 ОП-МП-04 | 0,7 |
| 5. | Юл буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-05 | 0,4 |
| 6. | Мәктәп яны ур. | 92-633-416 ОП-МП-06 | 0,3 |
| 7. | Яшьләр ур. | 92-633-416 ОП-МП-07 | 0,6 |
| 8. | Болын буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-08 | 0,6 |
| 9. | Яр буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-09 | 0,7 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Май ур. | 92-633-416 ОП-МП-10 | 0,9 |
| 11. | Кыр буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-11 | 0,3 |
| 12. | Посадка буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-12 | 0,2 |
| 13. | Тукай ур. | 92-633-416 ОП-МП-13 | 0,4 |
| | **Чишмә-Баш авылы** | | |
| 1. | Үзәк ур. | 92-633-416 ОП-МП-14 | 2,0 |
| 2 | Җиңү ур. | 92-633-416 ОП-МП-15 | 1,6 |
| 3 | Аргыяк ур. | 92-633-416 ОП-МП-16 | 1,4 |
| 4 | Тынычлык ур. | 92-633-416 ОП-МП-17 | 0,3 |
| 5 | Яңа ур. | 92-633-416 ОП-МП-18 | 1,1 |
| 6 | Яшьләр ур. | 92-633-416 ОП-МП-19 | 0,9 |
| 7 | Тукай ур. | 92-633-416 ОП-МП-20 | 0,5 |
| 8 | Посадка буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-21 | 0,3 |
| | **Кара-Елга авылы** | | |
| 1 | Үзәк ур. | 92-633-416 ОП-МП-22 | 0,5 |
| | **Купка авылы** | | |
| 1 | Яшьләр ур. | 92-633-416 ОП-МП-23 | 0,2 |
| 2 | Пролетар ур. | 92-633-416 ОП-МП-24 | 0,8 |
| 3 | Совет ур. | 92-633-416 ОП-МП-25 | 3,7 |
| | **Аш-Бужи авылы** | | |
| 1 | Яшьләр ур. | 92-633-416 ОП-МП-26 | 1,3 |
| 2 | Юл буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-27 | 0,7 |
| 3 | Көнчыгыш ур. | 92-633-416 ОП-МП-28 | 0,1 |
| 4 | Кыр буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-29 | 0,6 |
| 5 | Үзәк ур. | 92-633-416 ОП-МП-30 | 1,5 |
| 6 | Яшьлек ур. | 92-633-416 ОП-МП-31 | 0,5 |
| | **Адай авылы** | | |
| 1 | Үзәк ур. | 92-633-416 ОП-МП-32 | 0,6 |
| 2 | Мәктәп ур. | 92-633-416 ОП-МП-33 | 0,7 |
| 3 | Татарстан ур. | 92-633-416 ОП-МП-34 | 0,8 |
| 4 | Кояшлы ур. | 92-633-416 ОП-МП-35 | 0,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | Эшчеләр ур. | 92-633-416 ОП-МП-36 | 0,1 |
| 6 | Яшьләр ур. | 92-633-416 ОП-МП-37 | 0,5 |
| 7 | Болын буе ур. | 92-633-416 ОП-МП-38 | 0,4 |

Транспорт инфраструктурасы объектлары белән заманча тәэмин ителешне анализлау.

Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 2021 елга җиңел һәм йөк автомобильләре саны 1178 берәмлек тәшкил итә, шул исәптән җ
иңел автомобильләр – 1111, йөк автомобильләре – 67 һәм алга таба үсеш тенденциясе бар.

## 5. ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮНЕҢ ПРИНЦИПИАЛЬ ВАРИАНТЛАРЫ ҺӘМ МАКСАТЧАН КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ БУЕНЧА БӘЯЛӘҮ

Шәхси торак төзелеше өчен территорияләр арту сәбәпле, урам-юл челтәренә йөкләнеш артачак.

Тышкы автомобиль юллары челтәрен үстерү буенча проект карарлары поселокларны тотрыклы эчке һәм тышкы транспорт элемтәләре белән тәэмин итә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына ремонт чараларын үткәрүдән гыйбарәт.

## ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮНЕҢ МАКСАТЧАН КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

Зур Сәрдек авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасы системасының максатчан индикаторлары һәм үсеш күрсәткечләре.

3 нче таблица

| Индикаторлар төркеме | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026-2030 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халык өчен транспорт хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге критерийлары | Автомобиль урамнары һәм юллар системасы | км | 37,77 | 37,77 | 37,77 | 37,77 | 37,77 |
| Урам-юл челтәрен үстерүгә ихтыяҗ күрсәткечләре | Урам-юл челтәренең гомуми озынлыгы | км | 37,77 | 37,77 | 37,77 | 37,77 | 37,77 |
| Урам-юл челтәре кулланучыларын колачлау дәрәҗәсе күрсәткечләре | Транспорт белән тәэмин ителеш | Берәмлек/1000 кеше | 238 | 240 | 245 | 246 | 250 |
| | Юл хәрәкәте иминлеге | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Урам-юл челтәренең ышанычлылыгы күрсәткечләре | Челтәрләрне реконструкцияләү күләме (бер ел эчендә)* | км | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

## 6. ҖИРЛЕКНЕҢ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ИСЕМЛЕГЕ һӘМ ЧИРАТЫ.

Генплан нигезендә, җирлекнең кирәкле транспорт элемтәсен тәэмин итә торган һәм билгеләнеше һәм параметрлары буенча классификацияләнгән, үсеп килүче транспорт агымнарын, шулай ук тышкы автомобиль юлларына чыгуны тәэмин итә торган урам-юл челтәренең гамәлдәге структурасын саклап калып, автомобиль урамнары һәм юллары системасын булдыру күздә тотыла.

Торак пунктларда транспорт элемтәсенең куркынычсызлыгын, өзлексезлеген һәм уңайлылыгын тәэмин итү өчен, Генераль план нигезендә урамнар һәм юллар төзү каралган.

Урам һәм юл категорияләрен СП 42.13330.2011 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү. СНиП 2.07.01-89 актуальләштерелгән редакциясе» 9 нчы таблицада китерелгән классификация нигезендә билгеләргә кирәк

- төп (главные) урамнар;
- торак төзелешендәге урамнар: төп (основные);
- торак төзелешендәге урамнар: икенче дәрәҗәле;

4 нче таблица

| № т/б | Автомобиль юлы яки урам исеме | Озынлыгы, км | | | | Автомобиль юлы классы | Автомобиль юлы категориясе ... |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Шул исәптән: | | | | |
| | | | а/б | Щеб, грав. | Грунт | | |
| | **Зур Сәрдек авылы** | | | | | | |
| 1. | Узәк ур. | 5900 | 5900 | - | - | гади типтагы юл | Төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 2. | Мәктәп ур. | 900 | 360 | 540 | - | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 3. | Тау асты ур. | 1950 | - | - | 1950 | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 4. | Тынычлык ур. | 720 | - | 720 | - | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 5. | Юл буе ур. | 440 | - | 440 | - | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 6. | Мәктәп яны ур. | 300 | - | 300 | - | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 7. | Яшьләр ур. | 680 | - | 680 | - | гади типтагы юл | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 8. | Болын буе ур. | 600 | - | 600 | - | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 9. | Яр буе ур. | 790 | - | 790 | - | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 10. | Май ур. | 910 | - | - | 910 | гади типтагы юл | Торак төзелешендәге урам |
| 11. | Кыр буе ур. | 315 | - | 315 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 12. | Посадка буе ур. | 210 | - | 210 | - | Гади типтагы юл | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 13. | Тукай ур. | 400 | - | - | 400 | гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| | **Чишмә-Баш авылы** | | | | | | |
| 1. | Үзәк ур. | 2080 | - | 2080 | - | Гади типтагы юл | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 2 | Җиңү ур. | 1611 | - | 1611 | - | Гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 3 | Аргыяк ур. | 1480 | - | 1480 | - | Гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 4 | Тынычлык ур. | 306 | - | 306 | - | Гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 5 | Яңа ур. | 1112 | - | 1112 | - | Гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 6 | Яшьләр ур. | 933 | - | 933 | - | Гади типтагы юл | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 7 | Тукай ур. | 521 | - | 521 | - | Гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| 8 | Посадка буе ур. | 354 | - | 354 | - | Гади типтагы юл | торак төзелешендәге урам |
| | **Кара-Елга авылы** | | | | | | |
| 1 | Үзәк ур. | 552 | - | 552 | - | Гади типтагы юл | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| | **Купка авылы** | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Яшьләр ур. | 256 | - | 256 | - | | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 2 | Пролетар ур. | 840 | - | - | 840 | | торак төзелешендәге урам |
| 3 | Совет ур. | 3747 | - | 3747 | - | | торак төзелешендәге урам |
| | **Аш-Бужи авылы** | | | | | | |
| 1 | Яшьләр ур. | 1350 | 1000 | 350 | - | | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 2 | Юл буе ур. | 728 | 398 | - | 330 | | торак төзелешендәге урам |
| 3 | Көнчыгыш ур. | 1030 | - | 1030 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 4 | Кыр буе ур. | 615 | - | 615 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 5 | Үзәк ур. | 1565 | - | 1565 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 6 | Яшьлек ур. | 502 | - | 502 | - | | торак төзелешендәге урам |
| | **Адай авылы** | | | | | | |
| 1 | Үзәк ур. | 650 | 650 | - | - | | төп урам, торак төзелешендәге урам |
| 2 | Мәктәп ур. | 760 | 760 | - | - | | торак төзелешендәге урам |
| 3 | Татарстан ур. | 800 | 420 | 380 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 4 | Кояшлы ур. | 560 | - | 560 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 5 | Эшчеләр ур. | 1085 | - | 1085 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 6 | Яшьләр ур. | 512 | - | 512 | - | | торак төзелешендәге урам |
| 7 | Болын буе ур. | 426 | - | 426 | - | | торак төзелешендәге урам |

Урам-юл челтәренең тәкъдим ителгән структурасы транспорт проблемаларын мөмкин кадәр хәл итә: торак пунктларны кирәкле элемтә белән тәэмин итә, төбәк автоюлларына уңайлы чыгу мөмкинлеген тәэмин итә, шулай ук, торак төзелешен әйләнеп үтеп, йөк һәм авыл хуҗалыгы транспорты хәрәкәте проблемасын хәл итә.

Транспорт инфраструктурасын үстерү буенча чаралар транспорт инфраструктурасы объектларын үстерүгә булган ихтыяҗлар нигезендә түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны паспортлаштыру һәм кадастр исәбенә алу;
- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы хуҗасыз автомобиль юлларын һәм аларга ясалма корылмаларны муниципаль милеккә рәсмиләштерү;
- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм андагы ясалма корылмаларны агымдагы ремонтлау;

күрсәткечләре, категорияләренә карап, юлларның эксплуатацион характеристикаларына карата стандартлар таләпләренә туры килә торган юл-урам челтәре участокларын саклау,

- Зур Сәрдек авыл җирлегенең генераль планы нигезендә юл-урам челтәрен төзү;

- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм андагы ясалма корылмаларны капиталь ремонтлау;

- җирлек территориясендә юл хәрәкәтен оештыру проектын эшләү;

җирлек территориясендә юл хәрәкәтен оештыру проектын кертү;

- җирлек торак пунктларының үзәк өлешендә каты өслекле җәяүлеләр тротуарлары ясау
;

– торак пунктлар арасында велосипед маршрутларын оештыру.

## 7. ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ ҮСЕШЕ ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ КҮЛӘМНӘРЕН ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАРЫН БӘЯЛӘҮ

2022-2030 елларга Зур Сәрдек авыл җирлегенең урам-юл челтәре объектларын модернизацияләү буенча беренчел чараларга кирәкле акчаларның гомуми күләме 450 мең сум тәшкил итә.

транспорт инфраструктурасы буенча инвестицияләрнең план күләмен тормышка ашырыла торган һәм тормышка ашыру планлаштырыла торган урам-юл челтәрен үстерү проектларын исәпкә алып, шулай ук аларның финанс кертемнәренә булган өстенлекле ихтыяҗларын исәпкә алып бүлү 2022 – 2030 елларга эшләнгән. Алынган нәтиҗәләр (2022 ел бәяләре белән)

5 нче таблица

Зур Сәрдек авыл җирлегенең Транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру чорына инвестицияләр күләмен бүлү, мең сум.

| №т/б | Хезмәт төрләре | Программаны тормышка ашыруга инвестицияләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026-2030 | Барлыгы |
| 1 | Юлларны ремонтлау | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 10000 | 100000 |
| 2 | Юлларны карап тоту | 800 | 800 | 800 | 800 | 4000 | 8000 |
| 3 | Яктырту | 280 | 280 | 280 | 280 | 1400 | 2800 |

Транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыруга акчаларны хак куеп бүлү (оценочное распределение денежных средств) (2021 ел бәяләре белән)

6 нчы таблица

Зур Сәрдек авыл җирлеге программасын тормышка ашыруга акча җәлеп итү чыганаклары, мең сум

| №т/б | Атамасы | Барлык дәрәҗәдәге бюджетлар һәм шәхси инвесторлар | Шул исәптән, федераль бюджет | Шул исәптән, ТР бюджеты | Шул исәптән, җирле бюджет | Шул исәптән, бюджеттан тыш чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Юлларны ремонтлау | 2000 | 0 | 1600 | 400 | 0 |
| 2 | Юлларны карап тоту | 800 | 0 | 600 | 200 | 0 |
| 3 | Яктырту | 280 | 0 | 280 | 0 | 0 |

## 8. ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ ҮСЕШЕ ЧАРАЛАРЫНЫҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү аны гамәлгә ашыру вакыты дәвамында һәм аны тормышка ашыру тәмамланганнан соң ел саен гамәлгә ашырыла һәм үз эченә муниципаль программа чараларының үтәлеше дәрәҗәсен бәяләүне һәм муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләүне ала.

- җирлекнең транспорт инфраструктурасын үстерү;
- тормыш эшчәнлегенең башка өлкәләре белән балансланган һәм координацияләнгән;
- социаль-икътисадый үсеш өчен шартлар формалаштыру;
- юл хәрәкәте иминлеген арттыру;
- халыкка, икътисадый эшчәнлек алып баручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә транспорт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәлелеге сыйфаты;
- җирлекнең әйләнә-тирә мохитенә транспорт инфраструктурасының тискәре йогынтысын киметү.

## 9. ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН ПРОЕКТЛАУ, ТӨЗҮ, РЕКОНСТРУКЦИЯЛӘҮ ӨЛКӘСЕНДӘ ИНСТИТУЦИОН ҮЗГӘРТҮЛӘР, ЭШЧӘНЛЕКНЕ ХОКУКЫЙ ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ ТӘЭМИН ИТҮНЕ КАМИЛЛӘШТЕРҮ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты Программа чараларын тормышка ашыру барышын гомуми контрольдә тота, шулай ук Программаны тормышка ашыру барышында оештыру, методик һәм контроль функцияләр башкара:

- чараларны финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын ачыклап, Программаны гамәлгә ашыру буенча ел саен үткәрелә торган чаралар планын эшләү;
- программа чараларын тормышка ашыруны вакыты, эчтәлеге, финанс чыгымнары һәм ресурслар буенча контрольдә тоту;
- программа чаралары комплексын гамәлгә ашыру буенча эшне методик, мәгълүмати һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.

Программаны тормышка ашыру кысаларында институциональ үзгәрешләр күздә тотылмый. Идарә структурасын, шулай ук транспорт инфраструктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү өлкәсендә эшчәнлекне тормышка ашырганда үзара бәйләнешләрнең характерын үзгәрешсез калдыру күздә тотыла.

Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын үстерүнең Программаның максатчан күрсәткечләренә ирешүгә юнәлдерелгән норматив-хокукый һәм мәгълүмати тәэмин ителешен камилләштерү барышында Россия Федерациясенең региональ һәм федераль законнарына даими мониторинг нигезендә шәһәр төзелеше проектлары нормативларына вакытында үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә кирәк.

Әлеге Программа транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне һәм рекомендацияләрне регламентлый торган законнар, карарлар, күрсәтмәләр, методик рекомендацияләр һәм башка норматив-хокукый актлар үз көченә кергәндә корректировкаланырга яисә яңадан каралырга тиеш.

Максатчан индикаторларны һәм күрсәткечләрне, куелган максатларга ирешү динамикасына һәм темпларына, тышкы мохиттә үзгәрешләргә, социаль-икътисадый шартларга һәм башка факторларга бәйле рәвештә корректировкалау мөмкинлеге карала.

Программаны мәгълүмат белән тәэмин итү массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар өчен дә, аерым гражданнар өчен дә программаны тормышка ашыру барышы һәм аның аерым чаралары турында мәгълүматның транспарантлыгы принцибын үтәп гамәлгә ашырыла. Әлеге Программа «Җирлекләрнең, шәһәр округларының Транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

Җирлекләрнең һәм шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплексылы үстерү программаларын эшләү һәм раслау мониторингын гамәлгә ашыру тәртибе Россия Транспорт министрлыгының 2016 елның 26 маендагы 131 номерлы боерыгы белән билгеләнгән.